ГЛАВА
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН», МЭР ГОРОДА
ЛЕНИНОГОРСКА

Кутузова ул., дом 1,
город Лениногорск, 423250

«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ
ЛЕНИНОГОРСК
ШӘҺӘРЕ МЭРЫ

Кутузов урамы, 1нче йорт,
Лениногорск шәһәре, 423250

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2017 елның «19» июне №62

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле төрләре һәм җирле үзидарә органнары исемлеген алып бару тәртибе турында

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 26.12.2008 ел, № 294-ФЗ Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль закон һәм «Лениногорск муниципаль районы " муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә карар бирәм:

1.Кушымта итеп бирелә торган түбәндәгеләрне расларга:

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле төрләре исемлеген һәм җирле үзидарә органнары исемлеген алып бару тәртибе;

муниципаль контроль төрләре һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары исемлеге рәвеше.

2. Әлеге карар Лениногорск муниципаль районының рәсми интернет-сайтында рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көннән үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе Н.Р. Залаковка йөкләргә.

Р.Г.Хөсәенов

И.Р.Хәйбрахманов
5-44-7

**«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башлыгы, Лениногорск шәһәре мэрының 2017елның 19 июнендәге 62 номерлы карары белән расланды**

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле төрләре исемлеген һәм җирле үзидарә органнары исемлеген алып бару тәртибе

1. Әлеге Тәртип муниципаль контроль төрләре исемлеген һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары исемлеген алып бару өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга сала (алга таба - Исемлек дип атала).

2. Исемлекне алып бару «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге администрациясе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3. Исемлек түбәндәге белешмәләрне үз эченә алырга тиеш:

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары гамәлгә ашыра торган муниципаль контроль төрләре турында;

муниципаль контрольнең тиешле төрләрен гамәлгә ашыруга вәкаләтле «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары исемнәре турында;

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең тиешле җирле үзидарә органнарына муниципаль контрольне гамәлгә ашыру вәкаләтләрен бирү турында муниципаль норматив хокукый актларының реквизитлары хакында.

4. Исемлекне алып бару түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

белешмәләрне исемлеккә кертү;

Исемлектәге белешмәләргә үзгәрешләр кертү.

5. Исемлекне раслау, аңа үзгәрешләр кертү «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге тарафыннан карар формасында хокукый акт кабул итү юлы белән гамәлгә ашырыла.

6. Белешмәләрне исемлеккә кертү өчен «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең тиешле җирле үзидарә органына муниципаль контрольне гамәлгә ашыру вәкаләтләрен бирү турында норматив хокукый акты нигез була.

Исемлектәге белешмәләргә үзгәрешләр кертү өчен түбәндәгеләр нигез була:

муниципаль контроль төренең исемен үзгәртү;

муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органы исемен үзгәртү;

тиешле җирле үзидарә органына муниципаль контрольне гамәлгә ашыру вәкаләтләрен бирү турында муниципаль норматив хокукый актның үз көчен югалтуын тану;

җирле үзидарәнең башка органына муниципаль контрольне гамәлгә ашыру вәкаләтләрен бирү турында муниципаль норматив хокукый акт чыгару;

җирле үзидарә органының муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләрен туктату.

8. Исемлеккә белешмәләр кертү, аңа үзгәрешләр «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге тарафыннан әлеге Тәртипнең 6, 7 пунктларында күрсәтелгән белешмәләрне Исемлектәге белешмәләргә кертү өчен нигезләр барлыкка килгән көннән алып биш эш көне эчендә кертелә.

9.Исемлек «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырыла.

**«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башлыгы, Лениногорск шәһәре мэрының 2017елның 19 июнендәге 62 номерлы карары белән расланды**

(Форма)

Аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль контроль төрләре һәм җирле үзидарә органнары исемлеге

| № т/н | җирле үзидарә органы гамәлгә ашыра торган муниципаль контроль төре | Муниципаль контрольнең тиешле төрен гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органы исеме | җирле үзидарәнең тиешле органына муниципаль контрольне гамәлгә ашыру вәкаләтләрен бирү турында норматив-хокукый акт реквизитлары |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 | Алкоголь продукциясен ваклап сату өлкәсендә муниципаль контроль | «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты | «Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт җайга салуы турында һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү хакында» 171-ФЗ номерлы Федераль законның 7 ст.1. |
| 2 | Муниципаль район чикләрендәге торак пунктлар чикләреннән тыш җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышын муниципаль контроль һәм муниципаль берәмлек территориясендә юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү | «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты | «Автомобиль юллары турында» 257 номерлы Федераль законның 13 маддәсенең 1 нче өлеше; «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131 номерлы Федераль законның 15 ст.5 п. |
| 3 | Муниципаль берәмлек территориясендә җирләрдән файдалануга | «Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ | Җир кодексының 72 статьясы; «Россия Федерациясендә |

| № т/н | җирле үзидарә органы гамәлгә ашыра торган муниципаль контроль төре | Муниципаль контрольнең тиешле төрен гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органы исеме | җирле үзидарәнең тиешле органына муниципаль контрольне гамәлгә ашыру вәкаләтләрен бирү турында норматив-хокукый акт реквизитлары |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| | муниципаль җир контроле | | җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131 номерлы Федераль законның 35 п., 15 ст. |
| 4 | Муниципаль торак фондыннан файдалануга һәм аның сакланышына муниципаль контроль | «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты | 14 ст.9 п.<br>Торак кодексы; |
| 5 | Мөмкин булган мөлкәтне билгеләү һәм аның сакланышы буенча муниципаль контроль | «Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ | Граждан кодексының 295 маддәсе |
| 6 | Гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмалары төзегәндә җир асты байлыкларыннан файдалануга һәм аларны саклауга муниципаль контроль | «Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ | «Җир асты байлыклары турында» 2395-1 номерлы Федераль законның 5 ст.5 п. |
| 7 | Муниципаль урман контроле | «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башкарма | Урман кодексының 84 һәм 98 статьялары;<br>«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» |

| № т/н | җирле үзидарә органы гамәлгә ашыра торган муниципаль контроль төре | Муниципаль контрольнең тиешле төрен гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органы исеме | җирле үзидарәнең тиешле органына муниципаль контрольне гамәлгә ашыру вәкаләтләрен бирү турында норматив-хокукый акт реквизитлары |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| | | комитеты | 131 номерлы Федераль законның 15 маддәсенең 29 п. |
| 8 | Күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен башкару | «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты | «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 214-ФЗ номерлы Федераль законның 23 ст.2 п.;<br>«Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт тикшереп торуын һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясы |